МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.03.2021 г.Казань № 154

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 13 апрелендә 7638 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламен-тына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, граж-даннарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.09.2014 №490, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №400, 08.06.2017 №348, 17.11.2017 №809, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №885, 08.07.2019 №532, 03.09.2019 №665, 14.11.2019 №1017, 28.02.2020 №142, 09.07.2020 №491, 08.10.2020 №708 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган

Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның 24
мартындагы 154 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде;

вакцинадан соң өзлегү фактын билгеләү турында медицина оешмасы бәяләмәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелде;

вакцинадан соң өзлегүләр аркасында гражданинның үлем фактын билгеләү турында медицина оешмасы бәяләмәсе, – вафат булган кешенең гаилә әгъзалары тарафыннан бирелә;

үлемне дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә һәм банкта ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр дә алар нотариус тарафыннан яисә документның төп нөсхәсен бирүче орган (оешма, учреждение) тарафыннан таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин.»;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында мәгълүматлар һәм инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында), шулай ук үлемне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда) алына.»;

3.3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Үзәк бүлекчәсе белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә хезмәттән файдаланучының аерым шәхси счетының иминият номеры турындагы һәм инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган мәгълүматларны электрон формада Россия Федерациясе Пенсия фондыннан соратып ала; үлемне дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне – вәкаләтле органнардан.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.4.1 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар рәсмиләштерү: әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча; әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча;

дәүләт хезмәте билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны имзалау өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе документларны карап тикшергәннән соң дәүләт хезмәтен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарга кул куя һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар имзалау өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган дәүләт хезмәтен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.»;

3.7.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

дәүләт хезмәте билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә: әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар өчен – 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча; әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнар өчен – әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча;

дәүләт хезмәте билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза салу өчен юлланган дәүләт хезмәте билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

3.7.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

Регламентка 4 нче, 5 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нчы кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе

_______________________________

_______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Вакцинадан соңгы өзлегүләр барлыкка килгәндә айлык акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар

№___________ «__» __________ 20__ ел.

_______________________________________________________________
(билгеләргә, билгеләүдән баш тартырга) (кирәклесен күрсәтергә)
вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә айлык акчалата компенсация
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

___________________ сум күләмендә.
_______________________________________________________________
(баш тарткан очракта, сәбәбен күрсәтергә)

Түләү ысулы
_______________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлеге җитәкчесе
__________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)
_________________________ ________________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече
___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)
_____________________________ _____________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп __________________________________________
(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча ________________________
(электрон почта адресы)

бүлек белгече _______________________ ___________
(Ф.И.А.) имза

Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе

_________________________________

_________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Вакцинадан соңгы өзлегүләр барлыкка килгәндә бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар

№___________ «__» __________ 20__ ел.

_____________________________________________________________________________
(билгеләргә, билгеләүдән баш тартырга) (кирәклесен күрсәтергә)

Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә бер бирелә торган пособие

_____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

__________________ сум күләмендә.

_____________________________________________________________________________
(баш тарткан очракта, сәбәбен күрсәтергә)

Түләү ысулы

_____________________________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлеге җитәкчесе

________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

___________________________ ______________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече

______________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

______________________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ______________________________________________
(телефон номеры)

электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ___________________________________________
(электрон почта адресы)

бүлек белгече _________________________ ____________
(Ф.И.А.) имза.».